РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Карамалинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 8,
Азнакаевский район,
с.Карамалы, 423301,
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 8нче йорт, Азнакай
районы, Карамалы авылы,
423301
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» октябрь 2025 ел** **№ 3**

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Таллы Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Карамалы торак пунктында теркәлгән, сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Карамалы авыл җирлегенең Таллы Бүләк торак пунктында Үзәк ур., 10 йорт адресы буенча урнашкан 2025 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Таллы Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп -Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетын;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 12 ноябрендә 11.00 сәгатьтә;

– гражданнар җыенын уздыру урыны- Таллы Бүләк авылы, Үзәк урамы, 10 йорт, Таллы Бүләк авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 30 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Таллы Бүләк авылы, Үзәк урамы, 10;

- сайлау хокукына ия Таллы Бүләк торак пунктында яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Таллы Бүләк торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Таллы Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясе өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, чүп җыю, стела сатып алу һәм урнаштыру);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материал сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру, үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, чүп җыю)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Карамалы авыл җирлегенең Таллы Бүләк торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Таллы Бүләк авылы, Үзәк ур, 10 (Мәдәният йорты бинасы) мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык

А.Р. Ногманов